**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 декабрь 2023 ел** **№4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 13 декабрендә 13.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында 2024 елда авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** ( шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, грейдирование, юлларны кышкы чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);;

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (шул исәптән язгы-көзге чорда чүп үләннәренчабу, каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- **- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (**шул исәптән суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү**);**

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын депосын һәм автоцистернаны тоту , ягулык-майлау материаллары, АЦ-40 (131) өчен запас частьләр сатып алу)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 102 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 53 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

позиция өчен-53 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
каршы позиция өчен - 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында гражданнар җыенын үткәрелгән дип таныргa.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны : «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында 2024 елда авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** ( шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, грейдирование, юлларны кышкы чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);;

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (шул исәптән язгы-көзге чорда чүп үләннәренчабу, каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- **су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (**шул исәптән суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү**);**

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын депосын һәм автоцистернаны тоту , ягулык-майлау материаллары, АЦ-40 (131) өчен запас частьләр сатып алу)», кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;
- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;
-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Гарифуллин